**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

29 март 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Ярәп авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 10 апрелендә 14 сәгать 00 минутка Ярәп авылы, Киров урамы, 9нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ярәп авылының Беренче Май урамында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2 2024 елның 10 апрелендә 15 сәгать 00 минутка Ярәп авылы, Киров урамы, 9нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Иванов урамындагы йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2024 елның 10 апрелендә 16 сәгать 00 минутка Ярәп авылы, Киров урамы, 9нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Киров һәм Новая урамнарындагы йортларда яшәүчләр өчен гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«Сез элек расланганнарга үзгәрешләр кертүгә ризамы:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 14.11.2023 ел, № 3 карары
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Ярәп авылында гражданнар Җыенының 14.11.2023 ел, № 4 карары,

түбәндәге редакциядә раслап:

«Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Ярәп авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан тыш., балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнар, СВОда катнашучылардан тыш һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

Ярәп авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

«РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ярәп авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова